-

СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«11» ноябрь 2025 ел Алабуга шәһәре № 16

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү турында» 2025 елның 15 октябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 24 статьясы, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 50 статьясы, Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 20 апрелендәге 221 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрү турында» 2025 елның 15 октябрендәге 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс үткәрүне - Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт адресында урнашкан Совет бинасында, 2025 елның 2 декабренә, 09 сәгать 00 минутка билгеләргә..».

1.2. 4.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясенең дүрттән бер

өлеше һәм конкурсны үткәрү шартлары (1 нче, 2 нче кушымталар).».

1.3. әлеге карарга кушымта нигезендә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

1.4. 2 нче кушымтаның 1 нче һәм 2 нче пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Конкурсны үткәрү датасы: 2025 елның 2 декабре.

2. Конкурсны үткәрү вакыты: 09.00 сәгатьтә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов

Алабуга муниципаль районы Советының
2025 елның 15 октябрендәге 9 нчы номерлы
карарына 1 нче кушымта
(Алабуга муниципаль районы Советының
2025 елның 11 ноябрендәге 16 нчы номерлы карары редакциясендә)

**Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе составының дүрттән бер өлеше**

1. Косов Александр Владимирович - Алабуга муниципаль районы Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе;

2. Мингалиева Рәзимә Тимерхан кызы - Илмәт авыл җирлегенең 4 нче сайлау округы депутаты; комиссия әгъзасы.